РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТОЙГИЛЬДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МУСЛЮМОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТОЙГЕЛДЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«04» нче июль 2024 ел Тойгелде авылы № 15

**«2024-2027 елларга Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Тойгелдеавыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Тойгелде авыл җирлеге Башкарма комитетының «20» нче июнь 2024 елдагы 14 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Тойгелде авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. «2024-2027 елларга Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Тойгелде авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының «20» нче июнь 2024 елдагы 14 нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 нче кушымтаның 5.3 пунктындагы 5 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 5.3. | Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арасында ел саен уздырыла торган конкурслар үткәрү һәм уңай иҗтимагый климат булдыру максатыннан массакүләм мәгълүмат чараларында үткәрелә торган чараларны яктырту | Җирлекнең Башкарма комитеты | Җирлек бюджеты (10 мең сум) | 2024 е.– 3 б.<br>2025 е.- 4 б.<br>2026 е.- 4 б.<br>2027 е. – 5 б. |

1.2. 1 нче кушымтаның 7 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Барлыгы - агымдагы финанслау 10 000,00 сум, шул исәптән:<br>- авыл җирлеге бюджеты - 10 000,00 сум.<br>Программаны район авыл җирлеге бюджетыннан финанслау күләме ел саен чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы законы нигезендә төгәллəштерелəчәк.<br>Финанслау күләме кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арасында ел саен уздырыла торган |

| | |
|---|---|
| | конкурслар уздыруга һәм уңайлы шартлар тудыру максатында массакүләм мәгълүмат чараларында уздырыла торган чараларны яктыртуга юнәлтелгән.<br>Программаны финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм, тиешле бюджетларның мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш. |

2. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районы муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районы
Тойгелде авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Фәйзуллина Э.Н.